| | |
|---|---|
| МЭР<br>ГОРОДА БАВЛЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

23.10.2024 Баулы шәһәре №2-м

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы шәһәр Советының 2023 елның 14 августындагы 105 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар үткәрү тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба-Проект) буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны билгеләргә.

2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар инициаторы – Татарстан Республикасы Баулы шәһәре мэры.

3. Иҗтимагый фикер алышулар срогын билгеләргә - 2024 елның 28 октябреннән 11 ноябренә кадәр.

4. Иҗтимагый фикер алышуда каралачак Проект экспозициясен 2024 елның 28 октябрендә ачырга.

4.1. Экспозициясенең уздыру урыны:

- Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 кабинет адресы буенча;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru), «Тематик бүлекләр, халык өчен мәгълүмат» өлешендә.

4.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында экспозицияне барып карау режимы, түбәндәге адрес буенча: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, эш көннәрендә Мәскәү вакыты буенча 8.30 - 11.30 һәм 13.30 - 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2024 елның 28 октябреннән 11 ноябренә кадәр, Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- иҗтимагый фикер алышулар оештыручыга язма рәвештә түбәндәге адрес бюуенча: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб.;

- электрон почта аша Bauly.arch@mail.ru.

6. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетын иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп билгеләргә (алга таба-иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы).

7. Иҗтимагый фикер алышулар оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамәне мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында www.Bavly.tatarstan.ru, тематик бүлекләр, халык өчен мәгълүмат вкладкасында бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, 2024 елның 28 октябреннән 11 ноябренә кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru тематик бүлекләр вкладкасында оештырырга;

7.4. Җәмәгать фикер алышулары тәмамланганнан соң, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында www.Bavly.tatarstan.ru иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе Соколов С.Ю.га йөкләтергә.

Баулы  шәһәр мэры И.И. Гозәеров